
# Кышлаучы кошлар

Максаты.

1.Балаларда кошларга карата мәрхәмәтлелек кайгыртучанлык хисе тәрбияләү

2.Тышкы билгеләренә  үз- үзләрен тотышларына, тавышларына карап,кышлаучы кошларны танып белү.

3. балаларда кышлаучы кошлар турындагы белемнәрен ныгыту.


Җәй шакылдый бу чүкеч
кыш шакылдый бу чүкеч
ничек чыдый бу чүкеч
Александр Козюков © 2008

# ТУКРАН


Тукран – урман кошы. Ул һәрвакыт хәрәкәттә. Тукран үзенең көчле томшыгы белән агачлардан бөҗәкләр эзли. Очлы тырнаклары ярдәмендә агачта нык утырып тора ала. Ә койрыгы аңа терәк булып тора. Тукранны “ урман доктары” дип атыйлар.



Гөлдер –гөлдер- гөлдергү,
кызыл тәпи –кемдер бу?

# КҮГӘРЧЕН

Күгәрченне кеше яши торган урыннарда очратырга мөмкин. Күгәрченнәр кайвакыт ояларын да өй кыекларында ясыйлар.
Без күбрәк күк күгәрченне беләбез.Аның каурыйлары ялтырап тора
Күгәрченнең тәпиләре кызыл. Күгәрчен дуслык һәм тынычлык символы булып тора.


Чырык –чырык чыркылдый
Бер җиргә дә ул китми.
Безнең белән дус яши,
Әйтегезче,ул ни?
ctypa.ucoz.ru

# ЧЫПЧЫК

Чыпчыкны кеше яши торган урыннарда очратырга мөмкин. Чыпчык күксел төстә. Юл крыйлардан басуларда үзенә бөртекләр табып туклана.


Кырау булсын,
Кырпак булсын,
Китмәс дустым
Җәен – кышын
Салмый сары
Алъяпкычын.

# ПЕСНӘК

Песнәкләрне авылда да,шәһәрдә дә очратырга мөмкин.Ул урманнарда, паркларда бакчаларда яши. Песнәк – кечкенә кош. Аның томшыгы көчле. Томшыгы ярдәмендә  песнәк агач кай-рысыннан бөҗәкләр чүпли. Песнәк үлән орлыгы, төрле җиләкләр белән туклана.шулай ук майлы ит ярата. Кыш көне песнәкләрне ашатырга, җимлекләр ясарга кирәк.



# КАРГА